КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 октябрь г.Казань № 820

«Ятим балалар өчен оешмада булуы тәмамланган балалар арасыннан затларга консультация ярдәме, психологик, педагогик, юридик, социаль һәм башка ярдәм күрсәтү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Ятим балалар өчен оешмада булуы тәмамланган балалар арасыннан затларга консультация ярдәме, психологик, педагогик, юридик, социаль һәм башка ярдәм күрсәтү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 10 октябрь, 820 нче
карары белән расланды

«Ятим балалар өчен оешмада булуы тәмамланган балалар арасыннан затларга консультация ярдәме, психологик, педагогик, юридик, социаль һәм башка ярдәм күрсәтү» дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты

## I. Дәүләт хезмәтен алучылар категорияләре

1.1. Ятим балалар өчен оешмаларда булуы тәмамланган балалар арасыннан затларга консультация ярдәме, психологик, педагогик, юридик, социаль һәм башка ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтен алучылар (алга таба - дәүләт хезмәте) булып ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 18 яшькә җиткән һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмадан чыгарылуга бәйле рәвештә оешма булуын тәмамлаган Россия Федерациясе гражданнары тора (алга таба - дәүләт хезмәтен алучылар).

## II. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар:

1989 елның 20 ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе тарафыннан расланган Бала хокуклары турында конвенция;

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

«Куллнучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Бушлай юридик ярдәм турында Федераль закон);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмалар эшчәнлеге турында һәм аларда ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру турында» 2014 елның 24 маендагы 481 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Педагог-психолог (мәгариф өлкәсендә психолог) һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 24 июлендәге 514н номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

әлеге Стандарт;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың уставы, локаль актлары.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.»

## III. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен дәүләт хезмәтен түләүсез күрсәтү турында килешү (алга таба - килешү) төзелә.

3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүчеләргә дәүләт хезмәтен күрсәтү турында килешү түбәндәге документлар нигезендә төзелә:

| Т/с | Документлар исемлеге | Документны бирүче оешма яки документны бирү өчен җаваплы затлар | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затның статусын раслаучы документ (булган очракта) | опека һәм попечительлек органнары, гражданлык хәле актларын теркәүнең территориаль органнары, суд | законнар нигезендә |
| 2. | Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмада 18 яшькә җиткәнче булу чоры турында белешмә (булган очракта) | дәүләт хезмәте алучы 18 яшькә җиткәнче булган ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешма | законнар нигезендә |
| 3. | Дәүләт хезмәте күрсәтелүченең шәхесен раслый торган документ | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | - | законнар нигезендә |

IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартларына таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәте ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда, аларга мәгариф оешмалары, медицина оешмалары һәм социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар керә, анда ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар күзәтү астына урнаштырыла, гамәлгә куючысы булып республика башкарма хакимият органнары тора торган ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү үзәкләрендә, алмаш гаиләләрне әзерләү һәм озату үзәкләрендә күрсәтелә (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма).

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып психологик, педагогик, юридик, социаль һәм башка ярдәм күрсәтү тора, ул дәүләт хезмәтен алучының мәсьәләләрен чишүгә яки чишүгә ярдәм итүгә юнәлтелгән, бу бирелгән сорауны җентекләп өйрәнү, индивидуаль озату картасын рәсмиләштерү, дәүләт хезмәтен алучы белән килешеп, телдән яки язмача рәвештә тәкъдимнәр бирү, шул исәптән диагностик тикшерү билгеләүдән гыйбарәт (психологик-педагогик ярдәм күрсәтү вакытында).

4.3. Дәүләт хезмәтен алучының шәхси үзенчәлекләрен диагностик тикшерү дәүләт хезмәтен алучының соравы буенча уздырыла. Дәүләт хезмәтен алучының шәхси үзенчәлекләрен диагностик тикшерү психолог, педагог-психолог бәяләмәсе буенча ике - биш очрашу дәвамында гамәлгә ашырыла. Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура дәүләт хезмәтен алучының журналда психологик тикшерүгә язылу датасына һәм вакытына туры килә. Процедураның нәтиҗәсе булып психологик тикшерү беркетмәләре тора. Диагностик тикшерү үткәргәннән соң язма рәвештә тәкъдимнәр белән бәяләмә бирелә.

4.4. Юридик ярдәм күрсәтү түләүсез юридик ярдәм турындагы Федераль законга һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың җирле актына туры китереп телдән һәм язмача рәвештә башкарыла.

4.5. Социаль һәм башка ярдәм күрсәтү телдән һәм язмача консультация формасында башкарыла. Социаль һәм башка ярдәм күрсәтүнең башка формалары дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың уставына һәм законнарына туры китереп, оешманың җирле акты белән билгеләнергә мөмкин.

4.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү әлеге Стандартның 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма белән дәүләт хезмәтен алучы арасында төзелгән шартнамә нигезендә регламентлаштырыла. Шартнамә тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмада саклауда кала, икенчесе дәүләт хезмәтен алучыга тапшырыла. Шартнамә күрсәтелә торган хезмәтләрнең рәвешләрен һәм күләмен, алар күрсәтелергә тиешле срокларны, шулай ук якларның җаваплылыгын билгели. Хезмәт күрсәтү дәүләт хезмәтен алучыга берничә тапкыр күрсәтелергә мөмкин. Һәр төгәл бер очракта консультацияләр эчтәлеге һәм саны шәхси рәвештә билгеләнә.

4.7. Дәүләт хезмәте дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың түбәндәге эш юнәлешләре буенча күрсәтелә:

психология, педагогика, юриспруденция, социаль һәм башка өлкәләрдә укыту семинарлары, тренинглар оештыру һәм үткәрү;

психологның телдән консультация бирүе, шул исәптән шәхси сыйфатларны диагностик тикшерү үткәрү, дәүләт хезмәтен алучы соравы буенча телдән яки язмача бәяләмә әзерләү;

дәүләт хезмәтен алучы соравы буенча педагогик хезмәткәргә телдән яки язмача консультация бирү;

законнарда каралган социаль ярдәм чаралары һәм аларны алу тәртибе буенча дәүләт хезмәтен алучыларга телдән яки язмача консультация бирү;

хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хезмәтен алучыларга телдән яки язмача консультация бирү.

## V. Дәүләт хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә таләпләр

5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмада санитар-эпидемиологик таләпләргә һәм нормаларга туры килгән бүлмәләр булырга тиеш. Биналар һәм бүлмәләр коммуналь-көнкүреш хезмәтләренең барлык төрләре, телефон элемтәсе белән тәэмин ителергә тиеш.

Территория төзекләндерелгән һәм яшелләндерелгән булырга тиеш. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма белән функциональ бәйләнеше булмаган корылмалар һәм биналар территориядә урнаштырылырга тиеш түгел.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма территориясендә кирәк булган очракта җыештыру үткәрелергә тиеш. Кышкы вакытта территорияне кардан чистарту кирәк булган очракта үткәрелергә тиеш, территориягә ком сибү рөхсәт ителә. Химик реагентлар куллану рөхсәт ителми.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма бинасында түбәндәге бүлмәләр каралган булырга тиеш:

дәүләт хезмәте күрсәтүче белгечләр кабинетлары;

администрация кабинетлары;

белгечләр өчен хезмәт-көнкүреш бүлмәләре.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың матди-техник җиһазлануы, шул исәптән оештыру-техник һәм программалы-методик тәэмин ителеше, оештыру техникасы (компьютер, принтер, ксерокс, сканер), видеоязмалар һәм слайдлар җыелмасы белән видео күрсәтү системасы, тавыш язмалары җыелмасы белән тавыш чыгару системасы; хуҗалык инвентары белән тәэмин итү һ.б. күздә тота.

5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмада санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлар, стандартлар, техник шартлар, башка норматив документлар таләпләренә җавап бирүче һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең тиешле сыйфатын тәэмин итүче диагностик җиһазлар, нәшрият продукциясе, мебель, техник һәм аудиовизуаль чаралар бар.

5.5. Махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура эксплуатация документлары нигезендә төгәл билгеләнү буенча файдаланыла, техник төзек хәлдә тотыла. Төзек булмаган махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура алыштырыла, ремонтлана

(ремонтланырга тиеш булса) яисә төзексезлеге һәм дәүләт хезмәтен алучының сәламәтлегенә куркыныч янаганда эксплуатациядән алына.

5.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмада психолог, педагог-психолог, социаль эш белгечләре, юристлар һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башка хезмәткәрләрнең кабинетларын җиһазлау шартлары :

индивидуаль консультацияләр өчен җиһазланган зонасы булган аерым кабинет каралган булырга тиеш;

дәүләт хезмәте алучылар өчен уңайлы урында, дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыручы дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма хезмәткәрләренең эш сәгатьләре турында мәгълүмат булырга тиеш.

5.7. Психологик, психологик-педагогик ярдәм күрсәтү вакытында дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма тикшерелгән психодиагностик методикаларны гына куллана.

## VI. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең куркынычсызлык таләпләре

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма законнар белән билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлгән булырга тиеш.

6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың бүлмәләре «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Дәүләт хезмәте алучылар өчен бүлмәләрне подвалларда һәм цоколь катларында урнаштыру рөхсәт ителми.

6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте алучыларның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында тормышы һәм сәламәтлеге өчен җаваплылы була.

6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма хезмәткәрләре кирәк булганда дәүләт хезмәте алучыларга беренчел медицина-санитар ярдәм күрсәтәләр.

6.5. Бүлмәләрнең техник хәле санитар-эпидемиологик нормалар һәм кагыйдәләргә, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә, хезмәт куркынычсызлыгына туры килергә тиеш, шулай ук бүлмәләр күрсәтелә торган дәүләт хезмәте сыйфатына тискәре йогынты ясый торган факторлардан (шул исәптән һава температурасының югары булуы, һава дымлылыгы, тузанлылык, пычрану, тавыш, вибрация) сакланган булырга тиеш.

6.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма полицияне ашыгыч чакыру төймәсе белән җиһазландырылган булырга тиеш.

Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма хезмәткәрләре дәүләт хезмәте алучыларны эвакуацияләү һәм коткаруны тәэмин итәләр.

6.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма түбәндәгеләр белән җиһазландырылган булырга тиеш:

автоматик янгын сигнализациясе;

янгын турында хәбәр итү системасы;

кирәкле янгын сүндерү чаралары;

шәхси саклану чаралары;

эвакуацияне оештыру өчен кирәкле чаралар.

6.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмада:

күренеп торган урыннарда янгын чыккан очракта кешеләрне эвакуацияләү планнары (схемалары) эленгән булырга тиеш;

дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма хезмәткәрләренең кешеләрне куркынычсыз һәм тиз эвакуацияләүне тәэмин итү буенча гамәлләрен билгеләүче инструкция булырга тиеш;

кимендә ярты елга бер тапкыр дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың эвакуациядә катнашучы барлык хезмәткәрләре белән практик күнегүләр үткәрелергә тиеш.

## VII. Дәүләт хезмәтен алучылар өчен аның мөмкинлеген тәэмин итүче таләпләр

7.1. Дәүләт хезмәтен алучыларны кабул итү күләме һәм структурасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт биреме белән билгеләнә.

7.2. Дәүләт хезмәтенә ихтыяҗ аны күрсәтүдән артып киткән очракта (ихтыяҗ ел дәвамында тәкъдимнән югары һәм дәүләт биременнән артмый) дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкинлегеннән өстенлекле рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү чиратлылыгы журналда алдан язылуның хронологик тәртибе белән көйләнә.

7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма, дәүләт хезмәтен алучыларның тормыш эшчәнлеге чикләүләреннән чыгып, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып, дәүләт хезмәтен иркен керү һәм алу мөмкинлеге булган транспортка уңайлы урыннарда урнашырга тиеш.

7.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың эш расписаниесе, хезмәт һәм ял режимын иң уңайлы итеп булдыру максатында, санитар-гигиена таләпләре һәм нормаларны исәпкә алып төзелә, шул ук вакытта дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмада дәүләт хезмәтен күрсәтү иртәнге 8.00 сәгатьтән иртәрәк башланмаска, ә кичке 20.00 сәгатьтән соңга калмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың эш режимы устав һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың башка локаль норматив актлары белән көйләнә.

7.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмада дәүләт хезмәтен алучыларның консультациягә алдан язылуы шәхсән, дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмага турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә яки телефон аша башкарыла. Мөрәҗәгать иткән вакытта консультация бирү мөмкинлеге булганда, консультация алдан язылусыз да күрсәтелергә мөмкин.

7.6. Дәүләт хезмәте инвалидларга, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларга күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен махсус шартлар оештыру тәэмин ителә, аларга дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү яки сурдотәрҗемәчеләр, тифлосурдотәрҗемәчеләр, дәүләт хезмәтен алучыны озатып йөрүчеләргә дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмага керү мөмкинлеген тәэмин итү кирә.

Хезмәт күрсәтүнең мөмкинлеге дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма хезмәткәрләре ярдәмендә тәэмин ителә.

## VIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителү дәрәҗәсенә таләпләр

8.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма штат расписаниесенә туры килгән квалификацияле белгечләр белән комплектланырга тиеш. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма белгечләрен комплектлау тәртибе гамәлгә куючы тарафыннан расланган штат саны кысаларында билгеләнә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма штат расписаниесендә социаль педагоглар, социаль эш белгечләре, педагог-психологлар (психологлар), юристлар һәм башка белгечләр вазыйфалары каралган булырга мөмкин.

8.2. Педагогик эшчәнлеккә һөнәри стандарт белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән белем дәрәҗәсенә ия булган затлар гына кертелә.

8.3. Белгечләрнең квалификациясен югары дәрәҗәдә даими (периодик, өч елга кимендә бер тапкыр) укыту һәм квалификация күтәрү курсларында укыту белән тәэмин итәргә кирәк. Һәр категория белгечләрнең үз хокукларын һәм бурычларын билгеләүче вазыйфаи инструкцияләре булырга тиеш.

8.4. Тиешле квалификация һәм профессионализм белән беррәттән, дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың барлык белгечләре югары әхлакый сыйфатларга, җаваплылык хисенә ия булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма белгечләре клиентка йөз тоту принципларын үтәргә, дәүләт хезмәте алучыларга максималь әдәплелек, игътибар, сабырлык, алдан күрүчәнлек, түземлелек күрсәтергә тиеш.

8.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма белгечләре эшкә кергәндә мәҗбүри медицина тикшерүе һәм билгеләнгән тәртиптә даими медицина тикшерүе узарга тиеш. Медицина тикшерүләреннән, һөнәри һәм гигиена әзерлегеннән читләшкән, медицина тикшерүләре һәм һөнәри гигиена әзерлеге нәтиҗәләре белән билгеләнгән үрнәктәге шәхси медицина кенәгәсе булмаган белгечләргә эшләү рөхсәт ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма белгечләре шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тиеш: эшкә рәсми-эшлекле стиль таләпләренә туры килгән чиста кием һәм аяк киемендә килергә.

Йогышлы авырулары булуда шикләнелгән белгечләр эшкә кертелми яки шунда ук эштән читләштерелә.

8.6. Педагогик эшчәнлеккә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары белән педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгәннәр;

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы, җенси кагылгысызлык һәм шәхеснең җенси иреге, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның һәм иҗтимагый әхлакның сәламәтлегенә, дәүләтнең конституциячел корылышы һәм иминлеге нигезләренә, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш) һөкем ителгән яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), Россия Федерациясе Хезмәт

кодексының 331 статьясындагы өченче өлешендә каралган һәм әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш;

бүтән аңлы рәвештә кылынган авыр яки үтә авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган, әмма Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясының өченче абзацында һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелмәгән кешеләр;

федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек белән каралган авырулары булган;

чит ил агентлары дип танылган.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы икенче өлешенең өченче абзацында һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (стационар шартларында психиатрия ярдәмен күрсәтүче медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, дәүләтнең конституциячел корылышы һәм иминлеге, тынычлык һәм кешелек иминлеге нигезләренә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы зур булмаган авыр җинаятьләр кылган өчен хөкем ителгән затлар һәм бу җинаятьләрне кылуда гаепләнү буенча җинаять эзәрлекләве акланмаган нигезләр буенча туктатылган затлар балигъ булмаганнарның мәгариф, тәрбияләү, аларны үстерү өлкәсендә, аларның ялын һәм сәламәтләндерүне, медицина белән тәэмин итүне, социаль яклауны һәм социаль хезмәт күрсәтүне оештыруда, балигъ булмаганнарның эшләре буенча республика комиссиясе карары һәм аларны тиешле эшчәнлек төренә кертү турында аларның хокукларын яклау булганда, балалар-яшүсмерләр спорты, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә хезмәт эшчәнлегенә кертелергә мөмкин.

## IX. Дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмати тәэмин итү таләпләре

9.1. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат Россия Федерациясенең «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 300-1 номерлы законы таләпләренә туры килергә тиеш.

9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың эшчәнлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре, дәүләт хезмәтләре күләме хакында мәгълүмат, дәүләт биремен үтәү турында, дәүләт хезмәте стандарты турында хисап дәүләт хезмәте алучы һәркем файдалана алырлык булырга тиеш.

9.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма дәүләт хезмәте алучыларга үзенең атамасы һәм урнашкан урыны турында мәгълүматны җиткерергә тиеш. Әлеге мәгълүмат Россия Федерациясе законнары белән каралган һәм халык өчен аның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүче теләсә кайсы ысул белән тәкъдим ителергә тиеш.

Дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмат белән тәэмин итү түбәндәгечә башкарыла:

Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманы гамәлгә куючының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге Стандартны урнаштыру;

дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма исеме һәм урнашу урыны, дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма эшчәнлеге, күрсәтелә торган дәүләт хезмәте (дәүләт биреме) күләме, дәүләт биремен үтәү турында хисаплар, дәүләт хезмәте стандарты хакында мәгълүматны дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында, дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманы гамәлгә куючыларның рәсми сайтында урнаштыру.

Мәгълүмати озату массакүләм мәгълүмат чараларында тематик басмалар хисабына тәэмин ителергә мөмкин.

9.4. Дәүләт хезмәте алучы башкарылган дәүләт хезмәте турында кирәкле һәм дөрес мәгълүмат таләп итәргә хокуклы.

9.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма, дәүләт хезмәтен алучыга дәүләт хезмәте турында үз вакытында дөрес мәгълүмат бирергә, дәүләт хезмәтен алу кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга тиеш. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат составына түбәндәгеләр керергә тиеш:

әлеге Стандарт;

дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтен алучыларның дәүләт хезмәте сыйфатына йогынты ясау мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма белгечләре белән дәүләт хезмәте алучыларның элемтә чаралары турында мәгълүма;

дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары;

дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың гарантия йөкләмәләре.

9.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың эшчәнлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турында мәгълүмат кирәк булган саен, әмма кимендә елга ике тапкыр яңартылырга (актуальләштерелергә) тиеш.

9.7. Дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу максатыннан дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмага шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итәләр.

## X. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

бу Стандартның III бүлегенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегендә китерелгән документларны тапшырмау;

дәүләт хезмәтен алучының хәзерге Стандартның 1.1 пунктында китерелгән дәүләт хезмәте алучылар категориясе характеристикаларына туры килмәве;

алкоголь яки наркотик исереклеге хәле;

дәүләт хезмәтен күрсәтү турында килешүне, дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма белән дәүләт хезмәтен алучы арасында төзелгән килешүне, законнарда һәм (яки) әлеге килешүдә күрсәтелгән нигезләрдә өзү.

10.2. Килешү өзелү нигезләренә карата күрсәткечләр шартнамә текстында булырга тиеш. Бер якның инициативасы белән килешүне өзү нигезләре булып килешү шартларын җитди һәм (яки) системалы бозу тора.

## XI. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфаты индикаторлары түбәндәге таблицада китерелгән:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик күрсәткече | Авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Дәүләт хезмәте алучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Ж_о}{Ж} \times 100\%$, монда: $Ж_о$ – хисап чорында кергән дәүләт хезмәтен алучыларның нигезле шикаятьләре саны; Ж – хисап чорында кергән дәүләт хезмәтен алучыларның гомуми шикаятьләре саны | дәүләт хезмәтен алучыларның шикаятьләрен һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматны анализлау | 0 | 9 |
| 2. | Хезмәтнең сыйфаты һәм үтемлелеге белән канәгатьләндерелгән дәүләт хезмәтен | процент | $\frac{О_к + О_д}{2 \times О_{общ}} \times 100\%$, монда: $О_к$ – дәүләт хезмәтләре | дәүләт хезмәте күрсәтүләрдән файдаланучыларны сораштыру | 90 | 9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | алучылар өлеше | | сыйфаты белән канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_д$ – дәүләт хезмәтләре мөмкинлеге белән канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_{гом}$ – сораштырылганнарның гомуми саны | нәтиҗәләре буенча | | |
| 3. | Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында санитар-эпидемиологик режим, янгын һәм электр куркынычсызлыгы таләпләрен бозу булу | берәмлек | контроль-күзәтчелек органнарының күрсәтмәләрендә теркәлгән бозулар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 8 |
| 4. | Профильле һөнәри белемгә ия белгечләр өлеше | процент | $\frac{П_о}{О_{кс}} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$П_о$ – профильле һөнәри белемгә ия белгечләр өлеше;<br>$О_{кс}$ – квалификацияле белгечләрнең гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 6 |
| 5. | Интернаттан соң озатуны гамәлгә ашыру өчен штат берәмлекләре белән тәэмин ителеш өлеше | процент | $\frac{П_о}{О_{кс}} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$П_о$ – интернаттан соң озатуны гамәлгә ашыручы белгечләр саны;<br>$О_{кс}$ – хезмәт- | кадрлар исәбе документлары, хезмәткәрләрне билгеләү турында боерыклар | 70 | 6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кәрләрнең гомуми саны | | | |
| 6. | Интернаттан соң озатуны гамәлгә ашыруда булган чыгарылышлар өлеше | процент | $\frac{C_o}{C} \times 100\%$, монда: $C_o$ – хисап чорында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән чыгарылышлар саны; C – хисап чорында дәүләт хезмәте күрсәтүче оешма чыгарылышлары саны | интернаттан соң озату буенча эш хисаплары, чыгарылышларның мөрәҗәгатьләрен исәпкә алу мәгълүматлары, интернаттан соң озату турында килешү | 50 | 8 |

## XII. Әлеге Стандартны үтәмәүгә карата шикаятьләрне бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозу турында шикаять (алга таба – шикаять) дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмага язмача кәгазьдә, электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма учредительләренә бирелә.

12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына), дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма җитәкчесенең, дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың рәсми сайтын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru), дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманы гамәлгә куючының рәсми сайтын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук укучыны, балигъ булмаган укучының ата-анасын (законлы вәкилен) шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаять законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.4. Шикаять, шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан, теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, белем бирү оешмасының, белем бирү оешмасының вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен алучыдан документлар кабул итүдә баш тартуына карата шикаять белдергән очракта йә җибәрелгән басма хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы

бозылуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

Шикаятьне теркәү дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың эш алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә шикаять килгән көннән өч календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

12.5. Шикаятьне законнар нигезендә карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә һәм аны кабул иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәте алучыга язмача һәм дәүләт хезмәте алучының теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, дәүләт хезмәте алучыга җавапта дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешма тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдә ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарылган гамәлләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатында дәүләт хезмәте алучы тарафыннан башкарылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, дәүләт хезмәтен алучыга кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.

## XIII. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе

13.1. Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XIV. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт биремен үтәү өчен дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешмага билгеләнгән елга каралган чаралар кысаларында, бушлай күрсәтелә.